**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**Исполнительного комитета**
**Верхнеуслонского муниципального района**

422570, село Верхний Услон, ул. Чехова д. 18
тел.: (884379) 2-21-51, факс: (884379) 2-23-15

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Югары Ослан муниципаль районынын**
**Башкарма комитет**
**ЖИТЭКЧЕСЕ**

422570, Югары Ослан авылы, Чехов ур., 18 нче йорт
тел.: (884379) 2-21-51, факс: (884379) 2-23-15

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от ____________________ №_________

«Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 81 статьясы, Югары Ослан муниципаль районы Уставы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. "Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турында" кушымтада бирелгән Нигезләмәне расларга
2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе

Л.С. Хәкимҗанов

Әзерләде һәм бастырып чыгарды
Колесова Е.Е.
4 нөсхәдә.

Татарстан Республикасы Югары
Ослан муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесенең
______ карары белән
Расланган

«Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турында» нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 81 статьясы нигезендә эшләнгән Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондыннан (алга таба - резерв фонды) акча бүлеп бирү һәм куллану тәртибен билгели.

2. Резерв фонды, көтелмәгән чыгымнарны һәм җирле әһәмияттәге чараларны финанслау өчен, Югары Ослан муниципаль районы бюджетында тиешле финанс елына каралмаган урыннарда төзелә.

3. Резерв фонды күләме Югары Ослан муниципаль районының чираттагы финанс елына (һәм план чорына) бюджет турындагы карары белән Югары Ослан муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләменең 3 проценттан артыгы күләмендә билгеләнә.

4. Резерв фонды акчалары финанслауга тотыла:

стихияле бәла-казалар һәм башка гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен бетерү буенча көтелмәгән чыгымнар, шул исәптән авария-торгызу эшләре уздыру;

социаль әһәмияттәге объектларда кичектергесез ремонт һәм торгызу эшләре;

социаль-мәдәни өлкәне, физик культураны һәм спортны үстерүгә ярдәм итү;

иҗтимагый оешмаларга һәм берләшмәләргә ярдәм итү;

җирле әһәмияттәге чаралар уздыру;

җирле әһәмияттәге проблемалар буенча очрашулар, симпозиумнар, күргәзмәләр һәм семинарлар уздыру;

гражданнарга бер тапкыр бирелә торган премияләр түләү һәм матди ярдәм күрсәтү, шул исәптән стихияле бәла-казалардан һәм янгыннан зыян алганда;

гуманитар ярдәм күрсәтү;

Югары Ослан муниципаль районының җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кагылышлы башка чаралар һәм чыгымнар.

5. Резерв фондыннан акчалар бүлеп бирү Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитетының структур бүлекчәләре, җирлекләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның һәм физик затларның эш-хисаплары һәм нигезләмәләре белән мөрәҗәгать итүләре нигезендә, кирәк була калса, экспертлар, комиссияләр һәм башкалар бәяләмәсе нигезендә, Башкарма комитет җитәкчесенә юлланган. Резерв фондыннан акчалар Башкарма комитет җитәкчесе күрсәтмәләре нигезендә бүлеп бирелә.

Резерв фондыннан акчалар бүлеп бирү турындагы карарлар Югары Ослан муниципаль районының башкарма-күрсәтмә органнары һәм оешмалары карамагындагы, әлеге чараларны гамәлгә ашыручы чаралар җитәрлек булмаган очракта кабул ителә.

Резерв фондыннан акчалар бүлеп бирү турындагы тиешле күрсәтмәдә ассигнованиеләрнең гомуми күләме һәм аларны алучыларга һәм уздырыла торган чараларга бүлү күрсәтелә. Боерыклар белән каралмаган максатларда акчалардан файдалану рөхсәт ителми.

6. Бүлеп бирелүче средстволарның күләмен күрсәтеп, резерв фондыннан акча бүлеп бирү турында тиешле күрсәтмә проектлары Югары Ослан муниципаль районы Финанс-бюджет Палатасы тиешле йөкләмәне алганнан соң 10 көн эчендә әзерләнә.

7. Резерв фондыннан акчалар җирле дәрәҗәдәге гадәттән тыш хәлләрне бетерү чараларын финанслауга бүлеп бирелә.

Гадәттән тыш хәл барлыкка килгән көннән алып 30 көннән дә соңга калмыйча муниципаль предприятиеләр һәм оешмалар, муниципаль район учреждениеләре муниципаль районның башкарма комитетына резерв фондыннан акчалар бүлеп бирүне сорап мөрәҗәгать итә алалар.

8. Җирлекләрнең җирле үзидарә органнары, башкарма комитетның структур бүлекчәләре һәм алар карамагына резерв фонды акчалары бүлеп бирелә торган оешмалар акчаларны максатчан файдаланган өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплы булалар.

9. Резерв фондыннан башкарылган чыгымнар бюджет классификациясенең тиешле бүлекләре һәм максатчан маддәләре буенча Югары Ослан муниципаль районы бюджетының үтәлеше хисаплылыгында чагыла.

10. Муниципаль районның башкарма комитеты резерв фонды акчаларын тоту турында квартал саен район Советына хәбәр итә.